МКУ «Управление образования» ИКМО «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования
«Центр внешкольной работы» муниципального образования
«Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан

Принято на заседании педсовета ЦВР
Протокол № 5
от 24 января 2025г
Н.А.Багаутдинов

Утверждаю
Директор ЦВР______
Приказ № 11-ОД от 24.01.2025 г

**Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа**
**Художественного направления**
**«Театр һәм балалар»**
**Возрастная категория учащихся 8-14 лет**
**Срок реализации – 1 год**

Составитель программы:
педагог дополнительного образования
Муллагалиева Алсу Виловна

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 40AEC05861182E737D9C211CA301938E
Владелец: Багаутдинов Наиль Азгарович
Действителен с 16.11.2023 до 08.02.2025

село Шугурово 2024 год



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 1 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Эчтәлек**

1. Аңлатма язуы..........................................................................................................3
2.  Уку планы...........................................................................................................5
3. Тематик планлаштыру..........................................................................................5-8
4.  Программа эчтәлеге...........................................................................................8
5.  Планлаштырылган нәтиҗәләр..........................................................................8-10
6.  Программаны гамәлгә ашыруның оештыру-педагогик шартлары.............10
7.  Аттестация  формасы / контроль...................................................................11
8.  Бәяләү материаллары......................................................................................11-13
9.  Әдәбият исемлеге.............................................................................................13-14
10. Кушымта (методик материаллар, календарь-уку графигы)........ ....................14



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 2 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01

## Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге норматив-хокук документларынага нигезләнеп төзелде:

- Конвенция о правах ребенка
- Конституция Российской Федерации (статьи 9,36,42,58,71,72,114)
- Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации»
- Санитарно-эпидемиологические правила и нормативы СанПиН 2.4.4.3172-14
- Концепция развития дополнительного образования детей (от 04.09.2014)
- Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года
- Указ Президента Российской Федерации от 29 мая 2017 года № 240 "Об объявлении в Российской Федерации Десятилетия детства"
- Приказ МО и Н РФ от 09.11.2018г № 196 «Об утверждении порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»
- Закон Республики Татарстан № 68-ЗРТ от 22 июля 2013 года «Об образовании»
- Постановление КБ РТ от 12 октября2011 №846 «О внесении изменений в отдельные постановления КБ РТ»
- Приказ МО и Н РТ № 1465/14 от 20 марта 2014 года «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования»
- Устав МБУ ДО «Центр внешкольной работы» МО «ЛМР» РТ
- Положение о разработке дополнительных общеобразовательных программ в МБУ ДО «Центр внешкольной работы» МО «ЛМР» РТ

**«Театр Һәм балалар»** түгәрәге укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырыла. «Театр Һәм балалар» драма түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучылар өчен оештырыла. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, кулдан матур киемнәр әзерләү һәм зәвыклы киенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Чөнки мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп, араларында матур җырлаучылар, биюгә оста кызлар-малайлар бар. Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы була. Әлеге программага нигезләп үткәрелгән түгәрәк эше укучыларга ярдәм итә, матур сөйли,аралаша, үз фикерләрен эзлекле әйтергә өйрәтә. Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы кулланыла Түгәрәктә йөрүче укучыларны балалар шагыйрьләре, әсәрләре белән тирәнрәк тыныштыру, аларның әсәрләрен күбрәк уку теләге уяту максатлары да күздә тотыла.

Укучылар шулай ук үткән темалар ярдәмендә иҗади эш итеп шигырь, әдәби әсәр, мәсәл укырга өйрәнеп, сәхнәдә күрә белү, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерә ала.

**"Театр һәм балалар"** драма түгәрәге берләшмәсе 8-14 яшьлек укучылар өчен оештырыла. Атнага 4 сәгать хисабыннан. (Барлыгы 112 сәгать)

**"Театр һәм балалар" түгәрәге программасының актуальлеге:** Кереп баручы стандартларының яңалыгы - белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп - түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

1. Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.
2. Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.
3. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү
4. Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу.
5. Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.
6. Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

**Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше -** әдәби-сәнгати (художественная)

Максат: Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру.Һөнәри омтылышларын,сәләтләрен ачарга,матур сөйли,үз фикерләрен эзлекле әйтергә өйрәтү.Театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү. кече яшьтәге мәктәп балаларында сәламәт Яшәү рәвеше принципларын формалаштыру һәм аек яшәү рәвешенең аларның физик һәм психик сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итүче өстенлекләрен аңлауларына ирешү.

Ү**стерелешле максат :**

1. Сәнгатьле уку һәм сөйләм кунекмәләрен үстерү.
2. Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.
3. Сәхнә осталыгын үстерү өстендә эшләү
4. Укучыларда,балаларда,яшҗләрдә физик һәм психик сәламәтлекнең ныклы булуына китерүче сәламәт яшәү принөипларын формалаштыру.

**Бурычлар:**

- Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
- Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 4 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.

- Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

- Аеруча балалар өчен язылган һәм классик әсәрләр сәхнәләштерү, иҗат итү.

- Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар,балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр алдында чыгышлар ясау.

- Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү

- Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгы арттыру, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләү;

- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;

- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү ;

- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация тәэсирле чараларын кабатлау теләге тудыру.

- музыка һәм хореография сәнгате нигезләре белән танышу;

- укучыларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышка ашыру;

- балаларның сәламәтлеген яхшырту;

- сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү

-Укыту барышында укучыларда сәламәт яшәү рәвешенә кергән: дөрес туклану, физик активлык, начар гадәтләр,аек яшәү профилактикасы турында өйрзтү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Түгәрәккә йөрүчеләр белергә тиеш:**

1. Театр сәнгате, анын төп узенчәлеге.
2. Татар театр сәнгате, анын тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы.
3. Милли театрыбыз, анын беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары).
4. Драма жанрлары.
5. Классик драма әсәрләре, классик драматурглар иҗаты.
6. Актерлык бурычы, образга керү һәм тоемлап сөйләү.
7. Режиссер күрсәтмәләрен аңлый, үти белү.
8. Мәдәниятне аңлый белүче, иҗади талантлы, әхлак сыйфатларына ия кеше булу.

Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре.

1. Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аера.
2. Татар театры тарихы, уткән юлы белән таныш.
3. Сәнгатьле сөйли, образга керә.
4. Актерлык талантына ия.
5. Иҗади һәм мөстәкыйль эшли, үз киңәшләрен башкаларга да бирә ала.
6. Драма төрләрен аера, классик әсәрләрне аңлый.
7. Сәхнә тормышы белән таныш, башка милләт театрлары белән дә кызыксына.



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 5 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Программаны гамәлгә ашыруның оештыру-педагогик шартлары.**

Матди-техник тәэмин итү:
санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар таләпләрен канәгатьләндерүче уку кабинеты; типик җиһаз, укыту чаралары, (проектор, музыкаль үзәк , ноутбук, көчәйткеч);
Методик яктан тәэмин итү:
- сәхнәләштерү буенча махсус әдәбият;
- фонотека;
- видеотека;
- уеннар картотекасы;
-тематик папкалар «Театр тарихы», «Күңелле сәхнә»,
«Әйләнә сәхнә, әйләнә», “Күренекле артистлар”
- бәйрәмнәрнең сценарий эшләнмәләре, уен программалары һ. б.;
-дидактик материал (таблица, фотолар, рәсемнәр, инструкцияләр һ.б.).

**Уку планы**

| | теория | практика | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| 1 ел | 29 | 83 | 112 |
| Барлыгы | 29 | 83 | 112 |

**Тематик планлаштыру**

| **№** | **Темалар** | **Сәгатьләр саны** | | **Вакыты** | **аттестация/контроль формасы** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **теория** | **практика** | | |
| **I.Кереш дәрес (2 сәгать)** | | | | | |
| 1 | Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. ТБ Инструктажы үткәрү. | 2 | | 2.10.24 | Сорап чыгу (опрос) |
| **II. Без - яшь артистлар. (14 сәг.)** | | | | | |
| 2 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре өстендә эш | | 2 | 4.10.24 | Әңгәмә |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 6 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Сәхнә серләренә өйрәнү. | 1 | 1 | 9.10.24 | Әңгәмә |
| 4 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре | 1 | 1 | 11.10.24 | Әңгәмә |
| 5 | Киенү-бизәнү осталыгы | 1 | 1 | 16.10.24 | Сорап чыгу |
| 6 | Язмалардан чыгышлар карау. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү | | 2 | 18.10.24 | Күзәтү |
| 7 | Татар халык иҗаты белән танышу | 1 | 1 | 23.10.24 | Әңгәмә |
| 8 | Костюмнар әзерләү | | 2 | 25.10.24 | Сорап чыгу |
| **III. "Без табигать баласы" Экологик тема (14 сәгать)** | | | | | |
| 9 | Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте | 2 | | 30.10.24 | Әңгәмә |
| 10 | Табигать һәм без | 1 | 1 | 1.11.24 | Әңгәмә |
| 11 | Кошларны таныйсыңмы? дип исемләнгән музыкаль театр-тамаша | | 2 | 8.11.24 | Чыгыш-әңгәмә |
| 12 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре өстендә эш. Рольләр өстендә эш | 1 | 1 | 13.11.24 | Күзәтү, әңгәмә |
| 13 | Репетицияләр ясау | | 2 | 15.11.24 | Күзәтү |
| 14 | Костюмнар әзерләү | | 2 | 20.11.24 | Күзәтү |
| 15 | Кошларны таныйсыңмы? дип исемләнгән музыкаль театр-тамаша белән сәхнәдә чыгыш ясау | | 2 | 22.11.24 | Чыгыш |
| **IV.Театрлар карау (2 сәг.)** | | | | | |
| 16 | Туфан Миңнуллин “Әлдермештән Әлмәндәр” театрын карау | 1 | 1 | 27.11.24 | Сорап чыгу |
| **V. Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге (36 сәг.)** | | | | | |
| 17 | Г.Камалның “Беренче театр” әсәрен видеоязмадан карау | 2 | | 29.11.24 | Чыгыш-әңгәмә |
| 18 | Г.Камал “Беренче театр” әсәреннән өзекне уку | | 2 | 4.12.24 | Әңгәмә |
| 19 | Рольләр бүлү<br>Рольләр өстендә эш<br>Репетицияләр | | 2 | 6.12.24 | Әңгәмә, чыгыш |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 7 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 20 | Декорацияләр өстендә эш. | | 2 | 11.12.24 | Күзәтү |
| 21 | Костюмнар әзерләү | | 2 | 13.12.24 | Күзәтү |
| 22 | Репетицияләр | | 2 | 18.12.24 | Чыгыш , әңгәмә |
| 23 | Дикция. Интонация. | 1 | 1 | 20.12.24 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 24 | Сөйләм темпы. Рифма. Ритм.Импровизация. | 1 | 1 | 25.12.24 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 25 | Диалог. Монолог. | 1 | 1 | 27.12.24 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 26 | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек | | 2 | 3.01.25 | Күзәтү |
| 27 | Сәхнәдә “Зәңгәр шәл” әсәрен уйнау | | 2 | 8.01.25 | Чыгыш |
| 28 | "Чәчәкләр аланында" сәхнә уенының эчтәлеге белән танышу. | 1 | 1 | 10.01.25 | Әңгәмә |
| 29 | Рольләргә бүлеп уку.<br>Репетицияләр ясау | | 2 | 15.01.25 | Чыгыш |
| 30 | Киенү-бизәнү осталыгы. | 1 | 1 | 17.01.25 | Әңгәмә |
| 31 | Декорациянең роле | 1 | 1 | 22.01.25 | Сорап чыгу |
| 32 | Репетицияләр ясау | | 2 | 24.01.25 | Чыгыш |
| 33 | Сәхнәдә чыгыш ясау | | 2 | 29.01.25 | Чыгыш |
| 34 | Пантонимнар | 1 | 1 | 31.01.25 | Әңгәмә Күзәтү |
| **VI** | **Сәламәт тәндә сәламәт акыл**. **(6 сәг**.) | | | | |
| 35(1) | Сәламәт яшәү рәвеше:физик активлык,дөрес туклану,чисталык һәм начар гадәтләрдән саклану. | 2 | | 5.02.25 | сорашу |
| 36(2) | Начар гадәтләрнең физик һәм психик сәламәтлеккә зыяны. | 2 | | 7.02.25 | сорашу |
| 37(3) | Аек яшәү рәвешенең өстенлеге:иммунитетны ныгыту,авыруларга | 2 | | 12.02.25 | Әңгәмә,сорашу |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 8 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бирешмәү,эмоциональ яктан тотрыклы булу. | | | | |
| | **VII. Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау**.(**30 с**әг.) | | | | |
| 38 | Сәхнәдә чыгыш ясау | | 2 | 14.02.25 | |
| 39 | Хайваннар турында татар халык әкиятләре белән танышу.”Иң якын җан дуслар” | 1 | 1 | 19.02.25 | Әңгәмә |
| 40 | Рольләр өстендә эшләү | 1 | 1 | 21.02.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 41 | Репетиция ясау | | 2 | 26.02.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 42 | Декорацияләр ясау | | 2 | 28.02.25 | Әңгәмә |
| 43 | Костюмнар өстендә эш | | 1 | 5.03.25 | Күзәтү |
| 44 | Ритмопластика.Әкиятне сәхнәләштерү | | 2 | 7.03.25 | Чыгыш |
| 45 | Сәхнәдә чыгыш ясау | | 2 | 12.03.25 | Чыгыш |
| 46 | Рус һәм татар язучыларының шигырьләрен уку | 1 | 1 | 14.03.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 47 | «Мәңге яши Тукай безнең күңелләрдә!» | 1 | 1 | 19.03.25 | Чыгыш |
| 48 | Спектакльләрне тудыручылар:язучы,шагыйрь, драматург | 2 | | 21.03.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 49 | Мәкальләр дөньясына сәяхәт | 1 | 1 | 26.03.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 50 | Театрларның төрләре белән танышу.Курчак театры | 1 | 1 | 28.03.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| 51 | Музыкаль театрлар | 1 | 1 | 2.04.25 | Әңгәмә |
| 52 | Цирк театры | 1 | 1 | 4.04.25 | Әңгәмә,сорап чыгу |
| **VIII.Йомгаклау ( 2 сәг.)** | | | | | |
| 53 | Йомгаклау.Иҗади эшләр | | 2 | 18.04.25 | Чыгыш |
| 54 | Йомгаклау. | | 2 | 23.04.25 | |
| 55. | Викторина | | 2 | 25.04.25 | |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 9 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 56. | Уеннар. | | 2 | 30.04.25 | |
| | **Барлыгы** | **36** | **76** | | |

## Программаның эчтәлеге

**I. Кереш. (2 сәг.)**

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.

**II. Без - яшь артистлар. (14 сәг.)**

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, язмалардан чыгышлар карау. Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Костюмнар әзерләү.

**III. "Без табигать баласы" Экологик тема**. ( **14 с**әг.)

Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте. Табигатьне саклауга өлеш кертү: тирә-юньнең чисталыгын саклау, агачлар утырту, чишмәләрне чистарту, кошларга, җәнлекләргә карата мәрхәмәтле булырга кирәклеген төшендерү.

Экологик темага кичә үткәрү. "Кошларны таныйсыңмы? дип исемләнгән музыкаль театр-тамаша өйрәнү, чыгыш ясау.

**IV. Театрлар карау (2 сәг.)**

**V.Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге(36 сәг)**

Татар театры тарихы, аның беренче адымнары, үткән юлы

Татар театрының бүгенгесе

Драма жанры төрләре

Әсәрне иҗат итәргә әзерләү, актерлык серләрен өйрәнү

Әсәрне сәхнәгә кую (актерлык талантын тикшерү, ныгыту)

Экскурсия, очрашулар

Театр бәйгеләренә әзерләнү

**VI.Сәламәт тәндә сәламәт акыл**. **(6 сәг**.)

Сәламәт яшәү рәвеше:физик активлык,дөрес туклану,чисталык һәм начар гадәтләрдән саклану.Физик активлыкныңсәламәтлек өчен мөһимлеге,аның төрләре,физик күнегүләрнең мисаллары,нагрузкалар күләме.

Дөрес туклануның сәламәтлеккә әһәмияте,төп туклану принциплары,аксым,май һәм углеводлар,витаминнар һәм минераллар ,азык өстәмәләре һәм якынча меню.

Гигиена:аның сәламәтлеккә әһәмияте,шәхси гиггиена кагыйдәләре,су процедурасы,ял һәм йокы,җәмәгать урыннарында үзеңне дөрес тоту.

Начар гадәтләрнең физик һәм психик сәламәтлеккә зыяны.



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 10 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Гадәт төшенчәсе һәм аның кеше тормышындагы роле.

Начар гадәтләр:спиртлы эчемлекләр,тәмәке,наркотиклар куркыныч булуы һәм азагы.

Иптәшләрнең басымы һәм кире кага белү механизмнары.

Критик фикерләүне үстерү һәм дөрес юлны таба белү.

Сәламәт яшәү рәвеше һәм узеңнең исәнлегең өчен җаваплы булу.

Аек яшәү рәвешенең өстенлеге: иммунитетны ныгыту,авыруларга бирешмәү,эмоциональ яктан тотрыклы булу.

Иммунитетны ныгыту: организмны төрле яклап җимерүче спиртлы эчемлекләрдән, агуланудан, йөрәк авыруларыннан, инсульттан, ашказаны-бавыр бетү проблемаларыннан саклый.

Авыруларга бирешмәү: спиртлы эчемлекләрне кулланмау - сөт бизләре, калын эчәклек, бугаз, бавыр, йоткылык, авыз куышлыгы шешләрен булдырмауга китерә.

Организмның эмоциональ тотрыклылыгы: аек яшәү рәвешен алып бару - көтелмәгән стуацияләрдән, спиртлы эчемлекләрдән арыну, ми эшчәнлегенең нәтиҗәле эшләвен, хезмәтнең нәтиҗәлелеген үстерә.

**VII. Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау**.(**30 с**әг.)

. К.Тинчуринның “Зәңгәр шәл” әсәре, "Чәчәкләр аланында" сәхнә уенының эчтәлеге белән танышу, Хайваннар турында татар халык әкиятләре белән танышу.”Иң якын җан дуслар”, Мәкальләр дөньясына сәяхәт, «Мәңге яши Тукай безнең күңелләрдә!», Уен «Театр – экспромт»: «Колобок». Театрларның төрләре белән танышу:Курчак театры,Музыкаль театрлар,

Цирк театры, Рольләр өстендә эш,Репетицияләр, Дикорацияләр өстендә эш,

Костюмнар әзерләү.Дикция. Интонация. Сөйләм темпы. Рифма. Ритм.Импровизация.Диалог. Монолог.

**VIII.Йомгаклау. ( 8 сәг.)**

Тугәрәк шөгыльләре төрле формада уткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Әңгәмә, очрашу, экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла. Төп игътибар балаларның иҗади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

## Бәяләү материаллары

Аттестация һәм контроль формалары

Агымдагы контроль, башкаруны анализлау, күзәтү, әңгәмә, чыгышны анализлау, тематик конкурс, отчет чыгышлары



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 11 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Укучыларның белем дәрәҗәсен һәм шәхси үсешен мониторинглау (А.В.Хуторский буенча).**

| Күрсәткечләр (бәяләнә торган параметрлар) | Критерийлар | Бәяләнә торган сыйфатның көчлелеге дәрәҗәсе | Бәяләү баллары | Диагностика методлары |
|---|---|---|---|---|
| I. Укучының теоретик әзерлеге<br>1.1Теоретик белемнәр (уку-тематик план, программа буенча төп белемнәр буенча) | Баланың теоретик белеменең программа таләпләренә ярашлылыгы | Минималь дәрәҗә (бала программада каралган белем күләменең,1/2нән азрак үзләштергән );<br>Урта дәрәҗә (бала программада каралган белем күләменең,1/2нән күбрәк үзләштергән );<br>Максималь дәрәҗә (бала программада каралган белем күләмен тулысынча үзләштергән;) | 1<br>2<br>3 | Күзәтү, тестлар, контроль сораштыру |
| 1.2 Махсус терминологияне белү | Мәгънәлелек һәм махсус терминологияне кулланунық дөреслеге | Минималь дәрәҗә (бала, гадәттә, махсус терминнар кулланудан кача);<br>Уртача дәрәҗә (бала махсус терминологияне көнкүреш терминологиясе белән Максималь дәрәҗә (махсус терминнарны аңлы рәвештә һәм аларның эчтәлегенә тулысынча туры китереп куллана) | 1<br>3<br>3 | Күзәтү, тестлар, контроль сораштыру |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 12 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| II.Баланың практик әзерлеге:<br><br>2.1.Программада каралган гамәли күнекмәләр ( уку – тематик планы программаларның төп бүлекләр буенча ) | Программа таләпләре буенча практик белем һәм осталык туры килү | Минималь дәрәҗә (бала программада каралган белем күләменең,1/2нән азрак үзләштергән );<br><br>Урта дәрәҗә (бала программада каралган белем күләменең,1/2нән күбрәк үзләштергән );<br><br>Максималь дәрәҗә (бала программада каралган белем күләмен тулысынча үзләштергән;) | 1<br><br>2<br><br>3 | Контроль бирем |
| 2.3. Иҗади осталык | Практик биремнәрне үтәүдә иҗадилык | Иҗадилык үсешенең башлангыч (элементар) дәрәҗәсе (бала педагогның иң гади практик биремнәрен генә үти ала);<br><br>Репродуктив дәрәҗә (күбесенчә үрнәк нигезендә биремнәр башкара)<br><br>Иҗади дәрәҗә (иҗат элементлары белән практик биремнәр башкара) | 1<br><br>2<br><br>3 | Контроль күзәтү |
| III.Баланың гомуми уку осталыгы һәм күнекмәләре: | Әдәбиятны сайлап алуда һәм анализлауда мөстәкыйльлек | Минималь дәрәҗәдәге күнекмәләр (укучы әдәбият белән эшләгәндә җитди кыенлыклар кичерә, | 1 | Анализ |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 13 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | педагогның даими ярдәменә һәм контроленә мохтаж);<br><br>Урта дәрәҗә (педагог һәм ата-аналар ярдәмендә әдәбият белән эшли);<br><br>Максималь дәрәҗә (әдәбият белән мөстәкыйль эшли, аерым кыенлыклар кичерми) | 2<br><br>3 | |

**Кулланма әдәбият**

1. "Әдәбият белеменә кереш".
2. Татар халык әкиятләре.
3. "Тәрбия" газетасы.
4. "Ачык дәрес" газетасы.
5. "Җырлыйк әле" җыр китабы.
6. Х. Халиков "Зиһен ачкычлары"
7. "Мәктәп сәхнәсе" китабы.
8. Табышмаклар, тизәйткечләр, тел шомарткычлар.
9. "Сабантуй" газетасы.

10 Гомәр Бәширов "Туган ягым - яшел бишек"

11. Туфан Миңнуллин. Сайланма әсәрләр. Хәтер- 2008 нче ел

12. Татар драматургиясе (1960-1980 нче еллар). Сайланма әсәрләр ТаРИХ-2000

13 .Ренат Харис “Серле алан”.

Интернет чыганаклары

1. https://aldebaran.ru/genre/knigi_po_psihologii/detskaya_psihologiya/ «Детская психология»

2. http://knigi.link/vneuchebnaya-deyatelnost_1413/osnovnyie-tsennosti-funktsii-dopolnitelnogo-51901.htmlОсновные ценности и функции дополнительного образования .https://www.tspu.edu.ru/files/ped_news/методика обучения и воспитания в системе дополнительного образования детей
3.http://elib.gnpbu.ru/text/vozrastnaya-pedagogicheskaya-psihologiya_petrovskogo_1979/fs,1/ Возрастная и педагогическая психология
4.https://www.tspu.edu.ru/files/ped_news/методика обучения и воспитания в системе дополнительного образования детей
5.http://elib.gnpbu.ru/text/vozrastnaya-pedagogicheskaya-psihologiya_petrovskogo_1979/fs,1/ Возрастная и педагогическая психология

Кушымта

**Календарь уку графигы**

Уку елы башы: 1нче октябрь 2024ел

Уку елы ахыры: 30нчы апрель 2025 ел

Расписание

| Түгәрәк исеме | Класс | Көннәр | Вакыт | Җаваплы |
|---|---|---|---|---|
| ***Театр һәм балалар*** | 2, 4, 5,7,8 | Среда | 16.00-17.30 | Муллагалиева А.В. |
| | 2, 4, 5,7,8 | Пятница | 16.00-17.30 | Муллагалиева А.В |



Документ создан в электронной форме. № 21 от 30.01.2025. Исполнитель: Багаутдинов Н.А.
Страница 15 из 16. Страница создана: 30.01.2025 11:01
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 21 от 30.01.2025
Инициатор согласования: Багаутдинов Н.А. Директор
Согласование инициировано: 30.01.2025 11:02

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Багаутдинов Н.А. | | Подписано<br>30.01.2025 - 11:02 | - |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН